**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛЛӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ XV УТЫРЫШЫ**

**КАРАР № 27**

**Мәллә-Тамак авылы** **“22“ октябрь 2021 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы « Мәллә-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның «28» августындагы 2 нче номерлы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, шулай ук блокланган торак төзелеше өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләренең минималь күләмен 1 000 кв. м күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Мәллә-Тамак авл җирлеге Башлыгы Х.М.Хөсәенов